**«РАСЛЫЙМ»**
**Татарстан Республикасы**
**мәгариф һәм фән министры**

**_________________ И.Г.Һадиуллин**
**«___» _________ 2023 нче ел**

# Рус телендә белем бирү мәктәпләренең рус телле укучылары өчен туган (татар) телдән 2024 нче елда бердәм республика имтиханын уздыру материалларының күрсәтмә варианты

# Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения в 2024 году единого республиканского экзамена по родному (татарскому) языку для русскоязычных обучающихся школ с русским языком обучения

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Татар теленнән имтихан эшен башкаруга 180 минут вакыт бирелә. Имтихан эше 4 өлештән тора.

1 нче өлештә 8 бирем тәкъдим ителә (1-8 нче биремнәр). Алар укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. Башкару вакыты – 60 минут.

2 нче өлештә 9 бирем бирелә (9-17 нче биремнәр). Алар укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә. Башкару вакыты – 30 минут.

3 нче өлеш 12 биремнән тора (18 – 29 нчы биремнәр). Алар укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала. Башкару вакыты – 30 минут.

4 нче өлеш 2 биремнән тора (30 һәм 31нче биремнәр). Ачык типтагы 30 нчы бирем сөйләм ситуацияләренә караган репликалар язуны күздә тота. Башкару вакыты - 20 минут. 31 нче бирем укучыларның язма сөйләмен тикшерүдән гыйбарәт. Башкару вакыты - 40 минут.

**Уңышлар телибез!**

## Инструкция по выполнению работы

На выполнение экзаменационной работы по татарскому языку дается 180 минут. Работа состоит из 4-х частей (31 задание).

Часть 1 (задания по аудированию) включает 8 заданий на понимание аутентичных текстов (задания 1-8). Рекомендуемое время на выполнение данного раздела – 60 минут.

Часть 2 (задания по чтению) включает 9 заданий (задания 9-17). Рекомендуемое время на выполнение данного раздела – 30 минут.

Часть 3 (задания по лексике и грамматике) состоит из 12 заданий (задания 18-19). Рекомендуемое время на выполнение – 30 минут.

В части 4 (задания по письму) даны 2 задания (30 и 31). В задании 30 нужно написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией. Рекомендуемое время на выполнение – 20 минут. В задании 31 предлагается написать личное письмо. Рекомендуемое время на выполнение – 40 минут.

**Желаем успехов!**

## 1 нче өлеш

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**Сез җиде кыска диалог тыңларсыз. 1-7 нче сорауларга туры килгән җавапны билгеләгез. Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.**

**1. Дуслар кая барырга телиләр?**
1) стадионга
2) Спорт-кафега
3) паркка

**2. Кайсы дәрес булмаган?**
1) рус әдәбияты
2) физика
3) алгебра

**3. Наил нәрсәләр укырга ярата?**
1) фәнни мәкаләләр
2) сугыш турында әсәрләр
3) тормыш турында әсәрләр

**4. Спектакль сәгать ничәдә башлана?**
1) алтыда
2) алтынчы яртыда
3) биштә

**5. Тапшыру сәгать ничәдә башлана?**
1) сәгать алтыда
2) сәгать җиденче яртыда
3) сәгать җидедә

**6. Айгөл кем белән кунакка барган?**
1) дусты Алсу белән
2) күршесе белән
3) апасы белән

**7. Айгөл нәрсә укый?**
1) фәнни мәкалә
2) китап
3) журнал

**8.** ***Вы услышите пять высказываний. Установите соответствие между высказываниями каждого говорящего А – Г и утверждениями, данными в списке 1 - 6. Используйте каждое утверждение из списка 1-6 только один раз. В задании есть одно лишнее утверждение. Вы услышите запись дважды. Занесите свои ответы в таблицу.***

*Сез биш сөйләүчене ишетерсез. 1-6 саннары белән тамгаланган раслауларның кайсы сөйләүчегә туры килүен билгеләгез. Һәр раслауны бер генә тапкыр файдаланыгыз. Бер раслау артык булуын истә тотыгыз. Язманы ике тапкыр тыңарсыз. Җавапларыгызны җаваплар бланкына күчерергә онытмагыз.*

1. Сөйләүче метро турында әйтә.
2. Сөйләүче очкыч турында әйтә.
3. Сөйләүче поезд турында әйтә
4. Сөйләүче корабль турында әйтә.
5. Сөйләүче автомобиль турында әйтә.
6. Сөйләүче автобус турында әйтә.

Ответ:

| **Говорящий/ Сөйләүче** | **А** | **Ә** | **Б** | **В** | **Г** |
|---|---|---|---|---|---|
| **Утверждение/ Гыйбарә** | | | | | |

## 2 нче өлеш

***Прочитайте текст. Определите, какие их приведённых утверждений 9-16 соответствуют содержанию текста (1 – текстка туры килә), какие не соответствуют ( 2 – текстка туры килми) и о чём в тексте не сказано (3 – текстта әйтелми).***

*Текстны укыгыз. 9-16 нчы раслауларның текстның эчтәлегенә туры килүен (1 – текстка туры килә), туры килмәвен (2 – текстка туры килми) һәм текстта бу турыда мәгълүмат бирелмәвен (3 - текстта әйтелми) күрсәтегез.*

Бүген алар сыйныфлары белән китапханәгә экскурсиягә килделәр. Китапханәче апа аларны бик ягымлы каршылады. Укучылар да мондагы байлыкны күреп гаҗәпләнделәр. Шулкадәр күп китап буламыни?!

Таҗи китаплар турында Әминә апага сораулар бирде. Сораулар барысы да гади генә булсалар да, Әминә апа алар турында озаклап, матурлап аңлатты. Таҗи барысын бик игътибар белән тыңлады.

Таҗиның сораулары беткәч, Әминә апа Габдулла Тукайның “Шүрәле”сен кычкырып укыды. Бу вакытта Таҗи хәтта үзенең кайда утыруын да онытты. Аның күз алдында “Шүрәле”дәге серле урман һәм Кырлай егете генә калды…

Әминә апа, шигырьне укып бетергәч, сынаулы күзләре белән Таҗига карады. Малай бик гаҗәпләнгән һәм уйчан иде.

Сүзне Әминә апа үзе башлады:

- Я, Таҗи, әллә ошамадымы?
- Ошады. Моны да кеше язганмы, Әминә апа?
- Әлбәттә, кеше. Габдулла Тукай дигән бөек шагыйрь язган, - диде китапханәче.

*(Гариф Гобәйдән)*

**9.** Укучылар экскурсиягә барганнар.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**10.** Бик күп китаплар күргәч, балалар хәтта куркып калганнар.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**11.** Китапханәче укучыларга китаплар турында сөйләгән.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**12.** Таҗи китапханәчегә күп сораулар биргән.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**13.** Әминә апаның җавапларын малай игътибар белән тыңлаган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**14.** Китапханәче балаларга әкиятне кычкырып укыган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**15.** Таҗи да “Шүрәле” әкиятен яттан белгән.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**16.** Әсәрнең авторын Таҗи белгән.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**17.** ***Прочитайте тексты и установите соответствие между заголовками 1-7 и текстами А – Е. Запишите свои ответы в таблицу. Используйте каждую букву только один раз. В задании есть один лишний заголовок.***

*Текстны укыгыз. 1-8 нче җөмләләр белән А-Е абзацлары арасында тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавап күрсәтелгән саннарны таблицага языгыз. Бер җөмләне бер тапкыр гына файдаланыгыз. Бер артык җөмлә барлыгын онытмагыз.*

1. **Әбинең үтенече**
2. **Авылда ял итү**
3. **Станциягә барам**
4. **Укуның беренче көне**
5. **Поездга өлгермәдем**
6. **Кыяр**
7. **Әби һәрвакыт ашыга**
8. **Ял тиз үтте**

**А.** Ай-һай, тиз үтте бу җәйге каникул. Әле кайчан гына тышына “Ну, погоди!” төшерелгән рюкзакны асып, авылга кайткан идем. Инде капчыкны асып китеп тә барам.

**Ә**. Һәр елны каникулны мин авылда үткәрәм. Әби янында булам, аңа булышам. Бакчада эшлим, өй тирәсендә йөрим.

**Б.** Әбием әйбәт минем. Ләкин, нишләптер, ул бик – тынгысыз җан. Артыннан куалармыни - һәрвакыт ашыга. Ә мин бер дә ашыйкмыйм. Ашыгудан ни файда?

**В**. Авылга кайту белән үк әби: “ Кыяр утыртасы бар иде, улым, җирне әзерләп бир әле,” – диде.
- Ашыкма, әби, утыртабыз, - дим. – Хәзер чәй эчеп алыйм инде. Бераз ял итсәм дә ярар...

**Г.** Юк, әби, иртән дә шул кыяр, өч көннән соң да шул кыяр, атна буена “кыяр” дип әйтеп торды. Ул аптыраткач, ике атнадан соң кыяр өчен урын әзерләп бирдем. Дөрес, ул вакытта күршеләрнең кыяры чәчәк ата башлаган иде инде. Аның каравы, кеше тозлы кыяр ашаганда, без яшел кыяр ашадык. Әби әле күршеләрне дә сыйлаган.

**Д**. Күрәсезме: ашыкмаудан гел файда! Тик менә каникул гына ашыкты: тиз үтте. Иртәгә беренче сентябрь икән. Шуңа күрә бүген китәм. Казанда әни каршы алырга тиеш. Ә хәзер мин станциягә барам. Әнә күренә дә инде. Тагын әз генә барырга кирәк.

**Е**. Чү! Минем поезд туктаган түгелме? Әллә китәргә җыена инде? Кузгалды. Китә бит, китә. Китте. Бүген башка поезд да юк. Их! Мин ашыга-ашыга килдем бит инде. Тирләдем, йөгердем. Тик ни файда?! Үзегез күреп торасыз: ашыгудан файда юк. (*Вакыйф Нуриевтан*)

| **Текстлар** | **А** | **Ә** | **Б** | **В** | **Г** | **Д** | **Е** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Исемнәр** | | | | | | | |

### 3 нче өлеш

***Прочитайте текст. Преобразуйте слова, написанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами 18 – 23 так, чтобы они грамматически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами.***

*Текстны укыгыз. 18-23 нче биремнәрдә икенче баганада бирелгән сүзләрне җөмләдә кирәкле грамматик формага куегыз. Буш урыннарга языгыз.*

| | | |
|---|---|---|
| **18.** | Авылда йорт хайваннары абзарда, ә ... өйдә яшиләр. | ШӘҺӘР |

| | | |
|---|---|---|
| **19.** | Кемнәрдер өйдә эт, мәче тота, ... кенәри, папугайлар асрый. | ЧИТЛЕК |

| | | |
|---|---|---|
| **20.** | ... дә хайваннар күп. | БЕЗ |

| | | |
|---|---|---|
| **21.** | Без авылда ... . | ЯШӘРГӘ |

| | | |
|---|---|---|
| **22.** | Ишегалдында каз-үрдәкләр, әтәч һәм тавыкларыбыз йөри, Акбай кушаматлы этебез, Йомшак исемле ... бар. | ПЕСИ |

| | | |
|---|---|---|
| **23.** | Хайваннарны без бик ... . | ЯРАТЫРГА |

***Прочитайте текст. Преобразуйте слова, написанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами 24 – 29 так, чтобы они грамматически и лексически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами. Каждый пропуск соответствует отдельному заданию.***

*Текстны укыгыз. 24-29 нчы биремнәрдә икенче баганада бирелгән сүзләргә, ясагыч кушымчалар ялгап, яңа сүзләр ясагыз. Аларны җөмләдә кирәкле грамматик формага куеп языгыз. Һәр буш урын аерым биремгә туры килә.*

| | | |
|---|---|---|
| **24.** | Мәрьям әби бүген ... торды да тиз генә юынды. | ИРТӘ |
| **25.** | Ашыкмыйча гына ... чәй эчте. | ТӘМ |
| **26.** | Ул биш ... йортның беренче катында яши. | КАТ |
| **27.** | Тәрәзәдән һәммәсе күренә: кешеләр эшкә ашыгалар, “бишлеләр” алырга ... мәктәпкә баралар, автобус, трамвайлар йөри. | УКУ |
| **28.** | Ул барысына да ... көннәр, изге теләкләр теләде. | ХӘЕР |
| **29.** | Мәрьям әби, тәрәзәсен ачып, агачка кунган кошларны да … | СӘЛАМ |

## 4 нче өлеш

***Для ответа на задания 30 и 31 используйте бланк ответов № 2. При выполнении заданий 30 и 31 обратите внимание на то, что ваши ответы будут оцениваться только по записям, сделанным на бланке № 2. Записи в черновиках при проверке экспертом не учитываются.***
***Соблюдайте указанный объём письменной работы 31 (70 – 80 слов).***

*30 һәм 31 нче биремнәрне үтәү өчен, 2 нче номерлы җавап бланкларын файдаланыгыз. Җаваплар әлеге бланкларда язылганнар буенча тикшереләчәк. Караламадагы язмалар тикшерелми.*
*31 нче биремне үтәгәндә, язма эшнең күләмен истә тотыгыз (70-80 сүз).*

**30.** ***Напишите реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.***
*Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.*

1. Сообщите родителям, что ваш класс победил в конкурсе чтецов произведений Габдуллы Тукая.
2. Спросите у друга (подруги), где он (она) отдыхала в прошлое воскресенье.
3. Предложите младшему брату посмотреть фильм про диких животных Азии.
4. Попросите бабушку испечь вам блины.
5. Поздравьте классного руководителя с днем рождения.

**31. Сез татар дустыгыздан хат алдыгыз. Шушы сорауларга җавап биреп, аңа хат языгыз. Язма эшегез 70 – 80 сүздән торырга тиеш.**

*... Безнең укучылар волонтерлыкта катнашалар. Алар мәктәптә ярминкәләрне еш оештыралар. Анда сату өчен төрле әйберләрне укучылар үзләре ясыйлар, тегәләр, тәмле ризыклар пешерәләр. Ярминкәдән җыелган акчаны балалар йортына тапшыралар, шулай аларга ярдәм итәргә тырышалар. Волонтерлар балалар йортында тәрбияләнүчеләргә концерт һәм спектакльләр дә куялар, күчтәнәчләр алып баралар. Мин дә – волонтер. Укуны тәмамлагач та волонтер булып эшләргә телим.*

*... Ә син кемнәргә ярдәм итәсең?... Мәктәбегездә оештырылган ярминкәләрдә син ничек катнашасың?... Синеңчә, бу ярминкәләрнең файдасы нәрсәдә?*

## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

**Инструктор. Сез җиде кыска диалог тыңларсыз. 1-7 нче сорауларга туры килгән җавапны үрнәктәгечә билгеләгез.**
**Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.**

**Инструктор. Бер. Дуслар кая барырга телиләр?**

**Айгөл**: Наил, иртәгә кичен син нишлисең?
**Наил**: Өйдә булам.
**Айгөл**: Без сыйныфташлар белән стадионга футбол матчына барырга телибез. Безнең белән барасыңмы?
**Наил**: Бик яхшы фикер, ләкин анда билетлар юк инде. Мин иртән карадым. Футболны “Спорт- кафе”да карый алабыз. Анда күңелле була.
**Айгөл**: Бик кызганыч! Без саф һавада утырырга теләгән идек. Кафеда бик эссе булачак.
**Наил**: Алайса, әйдәгез, парктагы таблодан карыйбыз. Анда туры репортаж күрсәтәләр?
**Айгөл:** Яхшы, мин риза. Хәзер башкаларга да хәбәр итәм.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Ике. Кайсы дәрес булмаган?**
**Наил**: Айгөл, сәлам! Рус әдәбиятынан нинди өй эше бирделәр?
**Айгөл**: Сәлам, Наил! Әсәрне укып бетерергә куштылар.
**Наил:** Ә физикадан өй эше бармы?
**Айгөл:** Әйе, әлбәттә. Үткән дәрестә бирелгән эш. Нигә сорыйсың?
**Наил:** Мин бит үткән атнада мәктәптә булмадым, олимпиадага бардым, шуңа күрә өй эшләрен белмим.
**Айгөл:** Без физика дәресе вакытында ветераннар белән очрашуда булдык, яңа өй эше бирелмәде. Ә алгебра дәресендә яңа тема үттек. 283 һәм 284нче күнегүләр өй эшенә иде.
**Наил:** Рәхмәт, Айгөл! Мин аларны эшләрмен.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Өч. Наил нәрсәләр укырга ярата?**
**Айгөл:** Наил, син тагын китапханәгә барасыңмы?
**Наил**: Әйе, Айгөл, дөрес. Миңа Габдрахман Әпсәләмов повесте кирәк.
**Айгөл:** Син өченче көн берничә китап алган идең бит. Укып бетердеңмени?
**Наил:** Ул китаплар рус әдәбиятыннан сочинение язу өчен кирәк иделәр. Анда фәнни мәкаләләр җыентыгы, сүзлек алган идем. Ә хәзер “Яшел яр” әсәрен укырга телим.
**Айгөл:** Бу әсәр буенча сочинение язачаксыңмы?
**Наил:** Юк, миңа авыл тормышы турында китаплар уку ошый. Мөхәммәт Мәһдиев, Фатих Хөсни, Гомәр Бәширов әсәрләрен укыйм.
**Айгөл:** Сугыш, яшьләр тормышы турында да укырга яратасыңмы?
**Наил:** Күбрәк гади халык тормышы турында укыйм.
**Айгөл:** Кызык. Минем бу турыда китаплар укыганым юк.
**Наил**: Безнең тормыш белән чагыштыру өчен, укып кара әле. Минемчә, сиңа ошар.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Дүрт. Спектакль сәгать ничәдә башлана?**
**Айгөл:** Наил, без бүген сәгать биштә очрашабызмы?
**Наил:** Алтынчы яртыда очрашсак та өлгерәбез, Айгөл. Тукталыштан театрга кадәр биш минутта барып җитеп була.
**Айгөл:** Тамаша башланганчы, фойэда йөрергә, күргәзмәне карарга мөмкин. Театрга алданрак бармыйбызмы?
**Наил:** Анда спектакль башланганчы ярты сәгать алдан гына кертәләр. Алтынчы яртыга килсәк, бик яхшы була.
**Айгөл:** Ярый алайса, 17.30 да мин тукталышка килермен?
**Наил:** Бик яхшы, мин сине анда каршылармын.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Биш. Тапшыру сәгать ничәдә башлана?**
**Наил:** Айгөл, сәлам! Син ишеттеңме, бүген “Шаян ТВ” каналында безнең сыйныфташларны күрсәтәчәкләр.
**Айгөл**: Сәлам, Наил! Юк, ишетмәгән идем. Кем әйтте?
**Наил:** Миңа Алсу әйтте. Кичә алар ярышка барганнар иде бит, анда интервью биргәннәр, мәктәп турында сөйләгәннәр
**Айгөл**: Зур тапшыру булачакмы? Озак барамы? Башка сыйныфташларга да хәбәр итәргә кирәк.
**Наил:** Мин төгәл белмим. Ярты сәгатьлек интервью биргәннәр. Тапшыру яңалыклардан соң ук башланачак. Алсу шулай диде.
**Айгөл**: Яңалыклар кичке сәгать алтыда буламы?

**Наил:** Әйе. Яңалыклар ярты сәгать бара. Аннары сыйныфташларыбыз катнашкан тапшыру башланачак.

**Айгөл**: Рәхмәт! Хәзер мин башкаларга хәбәр язам.

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Алты. Айгөл кем белән кунакка барган?**

**Наил:** Айгөл, сәлам! Син кичә концертта булдыңмы? Сиңа безнең чыгыш ошадымы?

**Айгөл:** Исәнме, Наил! Әйе, сез бик матур җырладыгыз. Без дустым Алсу белән җырларыгызны бик рәхәтләнеп тыңлап утырдык.

**Наил:** Ә ни өчен дискотекага калмадыгыз? Мин сезне эзләдем, ләкин күрмәдем.

**Айгөл:** Концерттан соң мин өйгә кайттым. Кичә күршемнең туган көне иде. Ул апам белән мине кунакка чакырды. Шуңа күрә дискотекага кала алмадык.

**Наил:** Ә-ә-ә, алай икән. Дискотека бик күңелле булды. Без биедек, дуслар белән аралштык, конкурсларда да катнаштык. Мин анда элеккеге сыйныфташымны да очраттым.

**Айгөл:** Бик яхшы булган. Димәк, яхшы күңел ачкансыз.

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Җиде. Айгөл нәрсә укый?**

**Наил:** Айгөл, бүген кичен кинога барабызмы?

**Айгөл:** Нинди фильм була?

**Наил:** “Очыш” дигән фильм. Рекламасына караганда бик кызыклы фильм кебек күренә.

**Айгөл:** Кызганыч, минем коллоквиумга әзерләнәсем бар шул. Фәнни мәкаләне укырга кирәк.

**Наил:** Әле вакыт күп бит. Син мәкалә дә, китап та, журнал да укырга өлгерәчәксең. Дәреслектәге материалны мин сиңа юлда барганда сөйләрмен.

**Айгөл:** Рәхмәт! Алай булгач, барам. Ничәдә очрашабыз?

**Наил:** Сәгать алтыда тукталышта очрашыйк. .

**Айгөл:** Ярар.

**Наил:** Вакытыңны әрәм итмә, хәзер коллоквиумга әзерлән.

**Айгөл:** Ярар.

**[ 2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**8. Инструктор. Сез биш сөйләүчене ишетерсез. 1-6 саннары белән тамгаланган раслауларның кайсы сөйләүчегә туры килүен билгеләгез. Һәр раслауны бер генә тапкыр файдаланыгыз. Бер раслау артык булуын истә тотыгыз. Язманы ике тапкыр тыңларсыз. Җавапларыгызны җаваплар бланкына күчерергә онытмагыз.**

**Сөйләүче А**

Ул рельсларсыз йөри торган моторлы транспорт чарасы. Гадәттә тугыз яки күбрәк пассажирны йөртү өчен кулланыла. Ул бензин яки газ ярдәмендә йөри ала. Аны шәһәр эче транспорт чарасы буларак та, ерак араларны үтү өчен дә файдаланалар. Зурлыклары һәм төсләре ягыннан бу транспорт чаралары бик күп төрле була.

**Сөйләүче Ә**

Аны икенче төрле җир асты тимер юлы транспорты дип атыйлар. Ул зур шәһәрләрдә бар, һәм халыкны тиз арада шәһәрнең бер ноктасыннан икенче ноктасына алып барып җиткерү вазыйфасын үти. Беренче тапкыр аны 1963 елда Лондонда куллана башлаганнар. Уңайлыгын күргәч, башка зур шәһәрләрдә дә аны булдыру кирәк дип тапканнар.

**Сөйләүче Б**

Ул - дүрт тәгәрмәчле транспорт чарасы, кешеләр һәм йөк ташу өчен файдаланыла. Һәр юлда, шәһәр һәм авыл урамнарында аның бик күп төрләрен күрергә мөмкин. Бүгенге көндә һәр гаиләдә диярлек ул бар. Бу транспорт чарасы төсе, авырлыгы, кайчан, кайсы илдә һәм нинди заводта җитештерелүе белән аерыла.

**Сөйләүче В**

Бу – һавада оча торган канатлы транспорт чарасы. Ул пассажирларны тиз арада планетаның төрле почмакларына алып барып җиткерү өчен файдаланыла. Аның төрләре шактый күп: пассажирлар йөртү өчен кулланыла торганнары да, йөк ташый торганнары да, хәрби максатлардан файдаланыла торганнары да бар. Бүгенге көндә шәхси лайнерлар да, дәүләт компанияләренә караганнары да була.

**Сөйләүче Г**

Ул - су транспорт чараларының бер төре. Аны пассажирлар яки йөк ташу өчен дә, хәрби максатларда да файдаланлар. Алар зур елгаларда, диңгез һәм океаннарда йөзәләр. Кешеләр бу транспорт төрен сәяхәт вакытында бик яратып файдаланалар.

# ҖАВАПЛАР

| Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 3 |
| 2 | 2 |
| 3 | 3 |
| 4 | 1 |
| 5 | 2 |
| 6 | 3 |
| 7 | 1 |
| 8 | 61524 |
| 9 | 1 |
| 10 | 2 |
| 11 | 3 |
| 12 | 1 |
| 13 | 1 |
| 14 | 1 |
| 15 | 3 |
| 16 | 2 |
| 17 | 8271635 |
| 18 | ШӘҺӘРДӘ |
| 19 | ЧИТЛЕКТӘ |
| 20 | БЕЗНЕҢ |
| 21 | ЯШИБЕЗ |
| 22 | ПЕСИЕБЕЗ |
| 23 | ЯРАТАБЫЗ |
| 24 | ИРТӘН |
| 25 | ТӘМЛЕ |
| 26 | КАТЛЫ |
| 27 | УКУЧЫЛАР |
| 28 | ХӘЕРЛЕ |
| 29 | СӘЛАМЛӘДЕ |

**30 нчы биремне бәяләү критерийлары**
**Сөйләм ситуациясенә караган репликалар язу**

| *№* | *Бәяләү критерийлары* | *Баллар* |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| *I* | *Язылган текстның эчтәлеге* | |
| К1 | Сөйләм ситуациясенә караган репликаны формалаштыру | |
| | Имтихан бирүче, сөйләм ситуациясенә караган репликаны аңлап, җавабын дөрес формалаштырган.Коммуникатив бурыч төгәл үтәлгән.<br>Фактик хаталар юк. | 1 |
| | Имтихан бирүче сөйләм ситуациясенә караган репликаны дөрес формалаштырмаган.<br>***Яки***<br>Сөйләм ситуациясенә караган реплика өлешчә генә формалаштырылган<br>**Яки**<br>дөрес формалаштырмаган.<br>Яки<br>Фактик хаталар бар.<br>***Яки***<br>Имтихан **бирүче башка сөйләм ситуациясенә караган реплика язган**. | 0 |
| *II* | *Грамоталылык* | |
| К2 | Орфография һәм сөйләм нормаларының үтәлеше | |
| | Репликада орфографиягә тел нормаларының үтәлешенә караган хаталар (грамматик, орфографик, стилистик. пунктуацион) юк.<br>***Һәм/ яки*** төрле нормаларга караган 2 хата бар. | 1 |
| | Репликада тел нормаларының үтәлешенә караган 3 яки күбрәк хата бар.<br>**Яки**<br>Имтихан **бирүче башка сөйләм ситуациясенә караган реплика язган**. | 0 |
| Язма эш өчен максималь балл | | 2 |

## Шәхси хат язуны (31нче биремне) бәяләү критерийлары

| К | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| К1 | Коммуникатив бурычны үтәү | ***Эш тулысынча башкарылган***: 3 сорауга да тулы җавап бирелгән. Мөрәҗәгать итү, саубуллашу һәм имзалау фразалары дөрес сайланган. Алынган хатка рәхмәт белдерелгән. | ***Эш башкарылган:*** 3 сорауга да җавап бирелгән, әмма берсенә бирелгән җавап тулы түгел. Хат стилен бозган 1-2 төгәлсезлек бар ***һәм/яки*** алынган хатка рәхмәт белдерелмәгән. | ***Эш өлешчә башкарылган***: 2 сорауга гомуми җавап бирелгән, әмма 1 сорауга бирелгән җавап тулы түгел ***яки*** бер сорауга гомумән җавап юк. Хат стилен бозган 3 яки күбрәк төгәлсезлек бар, итагатьлелек формалары сакланмаган. | ***Эш башкарылмаган***: 2 сорауга җавап бирелмәгән ***яки*** текстның күләме тулмый. |
| К2 | Текстны оештыру | | Текст логик эзлеклелектә төзелгән һәм абзацларга бүленештә хаталар юк; тел чаралары дөрес кулланылган; хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килә. | Текст, гомумән алганда, логик эзлеклелектә төзелгән, ләкин логик бәйләнешләрдә ***һәм /яки*** абзацларга бүленештә ***яки*** хатның төзелешендә 1-2 төгәлсезлек бар. | Текст төзелешендә логик эзлеклелек сакланмаган; язма текст төзелешендә 3 яки күбрәк хата бар, ***яки*** хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килми. |
| К3 | Текстның лексик-грамматик төзелеше | Коммуникатив бурычны үтәү өчен кирәк булган төрле лексик һәм грамматик чаралар файдаланылган (текстны аңлауга зыян китермәгән 1-2 төгәлсезлек рөхсәт ителә). | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (3-4 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***яки*** тел хаталары юк, ләкин артык гади лексик һәм грамматик чаралар | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (5-6 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***һәм /яки*** текстны аңлауга зыян китерә торган 1-2 грамматик хата бар. | Текстны аңлауга зыян китерә торган хаталар 6 дан күбрәк. |

| К | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | кулланылган. | | |
| К4 | Орфография һәм пунктуация | | Орфографик һәм пунктуацион хаталар юк, **яки** текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 1-2 хата бар. | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 3-4 орфографик һәм пунктуацион хата бар. | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерә торган орфографик һәм пунктуацион хаталар 4 тән күбрәк. |

Шәхси хат язу биреме К1-К4 критерийлары буенча тикшерелә. Максималь **10 балл** алырга мөмкин.

Текстның эчтәлеге биремгә туры килмәсә (язма хат характерында булмаса, тәкъдим ителгән сорауларга җавап урынына башка мәгълүмат язылса, тәкъдим ителгән хат күчереп кенә язылса), бу бирем өчен 0 балл куела.

Хатның күләме **40** сүздән ким булса, К3 һәм К4 критерийлары буенча максималь балл куелмый.

Эшнең күләмен билгеләгәндә, беренче сүздән алып соңгысына кадәр (шулай ук адрес, язылу вакыты, имза да) исәпкә алына. **Хатта укучы үзенең чын исемен, адресын күрсәткән очракта эш тикшерелми.**